**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының**
**Өҗем авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

6 февраль 2026 ел №12

**Өҗем авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

2025 елның 29 декабрендәге 548-ФЗ номерлы «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында"гы һәм "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында"Федераль законның 29 һәм 65 статьялары, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында"гы 567 номерлы Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Өҗем авыл җирлеге Советы карар итте:

1. «Өҗем авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Советының 2021 елның 23 декабрендәге 35 номерлы карары белән расланган Өҗем авыл җирлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль турындагы нигезләмәгә (18.01.2024 №82, 12.05.2025 №112 үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1.1. Нигезләмәнең 1.7.1 нче пунктның 5 нче подпунктында** «аларның вәкилләреннән," сүзләреннән соң «үз-үзен җайга салучы оешма вәкилләреннән, әгәр контрольдә тотылучы зат өчен үз-үзен җайга салучы оешманың мәҗбүри әгъзалыгы каралган булса,»сүзләрен өстәргә.;

**1.2. 3.6.1 пунктының 2 подпунктын түбәндәге эчтәлекне яңа редакциядә бәян итәргә**:
“2) «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы нигезендә эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәр иткән контрольдә тотыла торган затларга яисә белешмәләре урнаштыруның классификацияләнгән чаралары реестрына кертелгән контрольдә тотыла торган затларга карата. Күрсәтелгән очракта мәҗбүри профилактик визит мондый хәбәрнамә тапшырылган көннән алып алты айдан да соңга калмыйча үткәрелә.»;

**1.3. 3.6.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә**: «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы Федераль законның 21 статьясындагы 5 өлешендә каралган тәртиптә Контрольдә тотылучы затка мәҗбүри профилактик визит уздыру турында ул башланырга егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.»;

**1.4. 4.2.2 пунктында** «мәҗбүри профилактик визитлар үткәрү ешлыгы» сүзләрен төшереп калдырырга;

**1.5. 4.2.4 пунктына** «контроль төре турындагы нигезләмәдә билгеләнгән очракларда, мәҗбүри профилактик визит елына бер тапкырдан артыграк булмаска мөмкин " сүзләрен өстәргә;

**1.6. 5.1 пунктның 5 подпунктында “мәҗбүри " сүзен төшереп калдырырга.**

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru. адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Өҗем авыл җирлеге башлыгы: Вәлиев А.Т.